**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№5335**
**07.10.2022**

Яр Чаллы шәһәренең һөнәри белем
бирү оешмалары һәм югары белем бирү
оешмалары студентлары арасында
террорчылыкка һәм экстремизмга каршы тору
проблемалары буенча тикшеренү эшләре һәм
проектлары (акцияләре һәм чаралары)
конкурсы үткәрү турында

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә террорчылык һәм экстремизм белән көрәшү буенча профилактика эшчәнлеген көчәйтү, шулай ук шәһәр территориясендә террорчылык һәм экстремизм күренешләре нәтиҗәләрен минимальләштерү һәм (яки) бетерү максатларында, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясы, «Террорчылыкка каршы тору турында» 2006 елның 6 мартындагы 35-ФЗ номерлы Федераль закон, шәһәр Уставының 9, 42 статьялары, Башкарма комитетның 2019 елның 31 октябрендәге 5632 номерлы карары белән расланган «2020-2022 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә террорчылык һәм экстремизмны профилактикалау, шулай ук террорчылык һәм экстремизм күренешләре нәтиҗәләрен минимальләштерү һәм (яки) бетерү» муниципаль программасы нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның яшьләр белән эшләү идарәсенә Яр Чаллы шәһәренең һөнәри белем бирү оешмалары һәм югары белем бирү оешмалары студентлары арасында террорчылыкка һәм экстремизмга каршы тору проблемалары буенча тикшеренү эшләре һәм проектлары (акцияләре һәм чаралары) конкурсын (алга таба-конкурс) 2022 елның октябре-ноябрендә үткәрергә.

2. Расларга:

1) конкурс үткәрү турында нигезләмәне, 1 нче кушымтада каралганча;

2) конкурсның оештыру комитеты составын, 2 нче кушымтада каралганча.

3. Башкарма комитетның финанс идарәсенә конкурсны оештыру һәм үткәрү чыгымнарын финанслауны 2022 елга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетының «Яшьләр сәясәте» 07.07 бүлегендә (бүлекчәсендә) каралган акчалар хисабына 18 000 (унсигез мең) сум күләмендә, 3 нче кушымтада каралганча тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Р.М. Хәлимовка, Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы С.Р. Мулюковага йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2022 елның 7 октябрендәге
5335 номерлы карарына
1 нче кушымта

Яр Чаллы шәһәренең һөнәри белем бирү оешмалары һәм
югары белем бирү оешмалары студентлары арасында террорчылыкка һәм
экстремизмга каршы тору проблемалары буенча тикшеренү эшләре һәм
проектлары (акцияләре һәм чаралары) конкурсын үткәрү турында
нигезләмә

1 бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1. Яр Чаллы шәһәренең һөнәри белем бирү оешмалары һәм югары белем бирү оешмалары студентлары арасында террорчылыкка һәм экстремизмга каршы тору проблемалары буенча тикшеренү эшләре һәм проектлары (акцияләре һәм чаралары) конкурсы (алга таба – конкурс) шәһәр студентларын террорчылык һәм экстремизмны профилактикалау белән бәйле социаль әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә җәлеп итү, яшьләр мохитендә толерантлык тәрбияләү максатында үткәрелә.

2. Конкурсны үткәрү өчен составы Башкарма комитет карары белән раслана торган оештыру комитеты төзелә.

2 бүлек. Катнашу шартлары һәм үткәрү тәртибе

3. Конкурста Яр Чаллы шәһәренең һөнәри белем бирү оешмалары һәм югары белем бирү оешмалары студентлары катнаша ала.

4. Конкурста катнашу өчен Яр Чаллы шәһәренең һөнәри белем бирү оешмалары һәм югары белем бирү оешмалары студентлары түбәндәгеләрне башкарарга тиеш:

1) террорчылыкка һәм экстремизмга каршы тору проблемалары буенча проект эшләргә, ул эшне тасвирлаган документ рәвешендә бирелә: социаль акция, чаралар комплексы, белем бирү юнәлешендәге очрашулар циклы һ.б. (алга таба - конкурс проекты);

2) террорчылыкка һәм экстремизмга каршы тору проблемалары буенча тикшеренү үткәрергә һәм конкурс эше әзерләргә, ул доклад, реферат, фәнни хисап яки статья рәвешендә бирелә (алга таба – конкурс эше).

5. Катнашу өчен заявкалар, конкурс проектлары һәм эшләре 2022 елның 30 октябренә кадәр (бу көнне дә кертеп) электрон адреска җибәрелә: moluchandco@gmail.com МОО «Молодые ученые города Набережные Челны» (423810, Яр Чаллы шәһәре, Академик Рубаненко урамы, 2 йорт (1/02), «НУР» ЯҮ» МАУ). Белешмәләр өчен телефон: (8552) 39-68-29.

6. Конкурс проектларын һәм эшләрен карап тикшерү 2022 елның 20 ноябренә кадәр бара.

7. Конкурс проектларын һәм эшләрен урында яклау, йомгак ясау һәм бүләкләү 2022 елның 24 ноябрендә була.

3 бүлек. Конкурс эшләренә таләпләр

8. Конкурс сайлап алуының төп критерийлары:

1) проблеманың актуальлеге, аның конкурс тематикасына туры килүе;

2) проблема буенча тикшеренү тирәнлеге;

3) теманы ачу дәрәҗәсе;

4) практик яки теоретик әһәмияте;

5) фәнни яңалыгы һәм куелган бурычны чишүнең оригинальлеге;

6) тәҗрибәне республика регионнарында трансляцияләү мөмкинлеге.

9. Конкурста түбәндәге эшләрне катнаштырырга рөхсәт ителми:

1) әлеге нигезләмә таләпләренә туры килми торган;

2) конкурска факсимиль элемтә буенча тәкъдим ителгән;

3) әлеге нигезләмәнең 2 бүлегендә күрсәтелгән сроктан соңрак кергән.

10. Материаллар электрон рәвештә тапшырылырга тиеш. Катнашучының заявкасы әлеге нигезләмәгә 1 нче кушымтада каралганча рәсмиләштерелә. Конкурс эшен рәсмиләштерү кагыйдәләре әлеге нигезләмәгә 2 нче кушымтада бирелгән.

11. Конкурс проекты проект хәл итәргә/кискенлеген киметергә тиешле проблеманың актуальлеген, тасвирламасын, максатын, проектның максатчан аудиториясен, календарь планын, төп чаралар исемлеген, көтелгән сан һәм сыйфат нәтиҗәләрен үз эченә алырга тиеш. Өстәмә мәгълүмат автор теләге буенча бирелә.

## 4 бүлек. Конкурска йомгак ясау

12. Конкурска йомгак ясау оештыру комитеты тарафыннан әлеге нигезләмәнең 8 пунктында күрсәтелгән критерийлар нигезендә 5 баллы система буенча үткәрелә.

13. Оештыру комитетының конкурста җиңүчеләр турында карары утырышта катнашучы оештыру комитеты әгъзаларының күпчелек тавышы белән ачык тавыш бирү юлы белән кабул ителә һәм беркетмә белән рәсмиләштерелә.

14. Конкурста җиңүчеләр «Конкурс проекты» һәм «Конкурс эше» номинацияләрендә 1, 2, 3 урыннар өчен дипломнар һәм акчалата призлар белән бүләкләнәләр.

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева

Яр Чаллы шәһәренең һөнәри белем
бирү оешмалары һәм югары белем
бирү оешмалары студентлары арасында
террорчылыкка һәм экстремизмга
каршы тору проблемалары буенча
тикшеренү эшләре һәм проектлары
(акцияләре һәм чаралары) конкурсын
үткәрү турында нигезләмәгә
1 нче кушымта

Катнашуга заявка

| Ф.И.А.и. (тулысынча) | |
|---|---|
| Белем бирү оешмасы | |
| Курс, төркем | |
| E-mail, тел. | |
| Номинациянең исеме (конкурс проекты/конкурс эше) | |
| Эшнең/проектның исеме | |
| Фәнни җитәкченең Ф.И.А.и. | |
| Гыйльми дәрәҗәсе, гыйльми исеме | |
| Email, тел. | |

Яр Чаллы шәһәренең һөнәри белем
бирү оешмалары һәм югары белем
бирү оешмалары студентлары арасында
террорчылыкка һәм экстремизмга
каршы тору проблемалары буенча
тикшеренү эшләре һәм проектлары
(акцияләре һәм чаралары) конкурсын
үткәрү турында нигезләмәгә
2 нче кушымта

Конкурс эшләрен рәсмиләштерүгә карата таләпләр

1. Конкурс эше 12 биткә кадәр күләмдәге доклад, реферат, фәнни хисап яки статья рәвешендә тапшырыла, шрифты Times New Roman, 14 кегль, юлара интервал - 1,5.

2. Эш түбәндәге бүлекләрдән торырга тиеш:

1) авторлар турында мәгълүмат (Ф.И.А.и. һәм белем бирү оешмасы, электрон почта);

2) эшнең исеме (баш хәрефләр, калын шрифт, үзәккә ориентлашу);

3) кереш;

4) методология һәм эмпирик база;

5) башка бүлекләр (ярдәмче бүлекләр сайлап алынган темадан чыгып, ирекле характерда булырга мөмкин);

6) дискуссия һәм йомгаклау;

7) библиография.

3. Барлык чит телләрдән кергән сүзләрнең чыганагы күрсәтелергә тиеш. Әдәбиятка сылтамалар текст буенча бара. Әдәбиятка сылтамалар квадрат җәяләрдә бирелә. Әдәбият исемлеге текст ахырында бирелә, аларның һәркайсы номер белән рәсмиләштерелә һәм кызыл юлдан языла.

Эшне рәсмиләштерү үрнәге:

СОЦИАЛЬ-НЕГАТИВ КҮРЕНЕШЛӘРНЕ ПРОФИЛАКТИКАЛАУ

*Иванов И.И., студент.*

*КФУ*

iivanov@mail.ru

Кереш

Текст. Текст. Текст. Текст. Текст. Текст. Текст. Текст. Текст. Текст. Текст. Текст. Текст. Текст. Текст. Текст. Текст. Текст. Текст. Текст. Текст. Текст. Текст. Текст. Текст. Текст. Текст. Текст. Текст. Текст [1].

Методология һәм эмпирик база

Текст. Текст. Текст. Текст. Текст. Текст. Текст. Текст. Текст.

…

Библиография

1. Лисовская, И.В. Преодолевая стигму? Ресоциализация «трудных» подростков и городская среда // Пермь университеты вестнигы. Философия. Психология. Социология. – 2018. – Т.№ 1 – С. 146 – 157

Башкарма комитетның
2022 елның 7 октябрендәге
5335 номерлы карарына
2 нче кушымта

Яр Чаллы шәһәренең һөнәри белем бирү оешмалары һәм
югары белем бирү оешмалары студентлары арасында террорчылыкка
һәм экстремизмга каршы тору проблемалары буенча тикшеренү эшләре һәм
проектлары (акцияләре һәм чаралары) конкурсының оештыру комитеты
составы

| № | Ф.И.А.и. | Вазыйфа |
|---|---|---|
| 1. | Видинеева<br>Ләйсән Әлфит кызы | Башкарма комитетның яшьләр белән эшләү идарәсе башлыгы |
| 2. | Фәйсханов<br>Рамил Рәшид улы | Шәһәр Хакиме ярдәмчесе (коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча) (килешү буенча) |
| 3. | Трянина<br>Полина Михайловна | Яр Чаллы шәһәренең «Нур» яшьләр үзәге» муниципаль автономияле учреждениесе директоры |
| 4. | Лундовских<br>Ирина Васильевна | «Диалог» психологик-педагогик ярдәм үзәге» муниципаль бюджет учреждениесе директоры |
| 5. | Рассолова<br>Елена Николаевна | Россия Фәннәр Академиясе Социология институтының кече фәнни хезмәткәре (килешү буенча) |
| 6. | Задворнов<br>Андрей Николаевич | философия фәннәре кандидаты, Казан федераль университетының Яр Чаллы институты доценты (килешү буенча) |
| 7. | Сабиров<br>Илшат Тәлгать улы | тарих фәннәре кандидаты, Яр Чаллы дәүләт педагогия университеты доценты (килешү буенча) |
| 8. | Шайнурова<br>Элина Рөстәм кызы | Яр Чаллы шәһәренең «Молодые ученые» РИО җитәкчесе (килешү буенча). |

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева

Башкарма комитетның
2022 елның 7 октябрендәге
5335 номерлы карарына
3 нче кушымта

Яр Чаллы шәһәренең һөнәри белем бирү оешмалары һәм югары белем бирү оешмалары студентлары арасында террорчылыкка һәм экстремизмга каршы тору проблемалары буенча тикшеренү эшләре һәм проектлары (акцияләре һәм чаралары) конкурсын үткәрүгә чыгымнар сметасы

| Учреждениенең исеме | Чыгымнар статьясы | Сумма (сум) |
|---|---|---|
| Яр Чаллы шәһәренең «Нур» яшьләр үзәге» муниципаль автономияле учреждениесе | Акчалата призлар:<br>«Конкурс проекты» номинациясе<br>1 урын - 3500 сум х данә<br>2 урын - 2500 сум х данә<br>3 урын - 1500 сум х данә<br><br>«Конкурс эше» номинациясе<br>1 урын - 3500 сум х данә<br>2 урын - 2500 сум х данә<br>3 урын - 1500 сум х данә | 15 000 |
| | Типография чыгымнары:<br><br>Дипломнар, рәхмәт хатлары А4, 30 данә * 20 сум<br>Катнашучы сертификаты А5, 10 данә * 10 сум<br>Стикерпак А5, 50 данә* 46 сум | 3 000 |
| | барлыгы: | 18 000 |

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева